СИШӘМБЕ
30
МАРТ
1943 ел.
№ 70 (6792)
Аерым номеры 20 тиен.

ВАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

АТ ТУРЫНДА

Авыл хуҗалыгын коллективлаштыру елларында авылда машина техникасы гаять үсте. Тракторлар, комбайннар, ашлык сугу машиналары һәм башка шундый бик күп катлаулы машиналар эшләп чыгару көн саен артып торды. Тракторлар, автомашиналар колхозларга, совхозларга һәм МТС ларга өзлексез агылып торды. Ниһаять, авылда күп кенә эш процесслары электр көченә күчерелде.

Ләкин аңа карап җанлы тарту көчләренең, шул исәптән атларның, әһәмияте, аның хуҗалыкта тоткан урыны һич тә кимемәде. Социалистик авыл хуҗалыгы үскән саен, колхозлар ныгый барган саен, киресенчә, атның әһәмияте күтәрелә барды. Бу бик табигый. Чөнки гөрләп үсә торган ил өчен, халык хуҗалыгының барлык тармаклары буенча гигант адымнар белән өзлексез рәвештә алга баручы безнең илебез өчен, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә елдан-ел яңадан-яңа уңышларга ирешүче колхоз строе өчен шулай кирәк иде.

Шуңа күрә дә партиябез һәм хөкүмәтебез, илебездә механик тарту көчләре үсеп торуга да карамастан, атлар санын арттыру өчен, атларның сыйфатын күтәрү өчен өзлексез кайгыртучанлык күрсәттеләр һәм хәзер дә күрсәтәләр.

Илбасар немец фашистларга каршы изге ватан сугышы тракторларның да һәм шулай ук атларның да бер өлешен фронтка җибәрүне таләп итте. Димәк, авылда да механик тарту көчләре дә һәм атлар саны да кимеде. Бу беркем өчен сер дә түгел һәм аңа гаҗәпләнергә дә урын юк. Ә шул ук вакытта авылда эш күләме һич тә кимемәде, киресенчә артты әле. Менә бу хәл бер үзе генә дә машиналардан тулысынча файдалану белән беррәттән ат үрчетүгә, булган атларны күз алмасы кебек саклауга, атлардан дөрес файдалануга аеруча җитди игътибар бирүне таләп итә.

Язгы чәчү вакыты килеп җитә. Ә быел, һәрберебезгә билгеле, язгы чәчүдә һәр атка туры килә торган эш нагрузкасы кечкенә түгел. Ул нагрузканы тулысынча үтәп, без быел язгы чәчүне, зур кыенлыклар булуга да карамастан, моннан элеккеге еллардагыга чагыштырганда берничә тапкыр яхшырак итеп башкарырга тиешбез. Чөнки язгы чәчү ул шул елгы югары иген уңышы өчен көрәштә төп чара булып тора. Язгы чәчү үз вакытында һәм барлык агротехника чараларын тулысынча җиренә җиткерен үтәлә икән — иген уңышы булачак, ә инде, киресенчә, язгы чәчү соңга калса, начар сыйфатлы итеп башкарылса, иген уңышын көтәргә урын калмаячак.

Шул ук вакытта атның фронт өчен дә бик күп кирәк булуын һәм киләчәктә дә кирәк булачагын бер генә минутка да хәтердән чыгарырга ярамый.

Әйе, хәзер атның әһәмияте чиксез зур. Ләкин, кызганычка каршы, кайбер урыннарда ат үрчетү эшенә, атларны язгы чәчүгә әзерләү эшенә һич тә әһәмият бирмиләр. Күптән түгел генә әле, язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы уңае белән, «Кызыл Татарстан» газетасының Шөгер районы хәбәрчеләре бу районның күп кенә колхозларында язгы чәчүгә атларны әзерләү эшенең барышы белән танышу өчен рейд оештырдылар. Рейд бу районның күп кенә колхозларында атларга карата иясезлек хөкем сөрүен, ат азыклары тәмам җитәрлек булуга да карамастан, күп кенә атларның коточкыч дәрәҗәдә ябык булулары, сбруйларның һәр атка карата аерым рәвештә көйләнмәгән булуы нәтиҗәсендә, ыңгырчак басу, камыт сугу кебек фактларның бик күп булуын күрсәтте. Менә хәбәрчеләр тарафыннан ныклап тикшерү үткәрелгән Микоян исемендәге колхоз. Иң элек шуны әйтергә кирәк, бу колхозның язгы чәчүгә әзерлеге зарланырлык түгел. Чәчү орлыклары җитәрлек бар, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт төгәлләнгән. Ә менә инде атларга килгәндә хәл шәптән түгел. Аларның күп кенә өлеше ябык. Ябык атларны, буаз бияләрне аерым тәрбиягә куймаганнар. Яки менә Биектау районының Пермяковский авыл советына караган «Искра» колхозын алыйк. Бу колхозда атлар беркемгә дә беркетелмәгән. Эштән кайткач та, атларны абзарга җибәрәләр дә шуннан соң иртә белән барып җиккәнчегә кадәр, ат абзарлары тирәсенә әйләнеп караучы да булмый. Шул ук районның Тукай исемендәге колхозында, тәрбия начар булганлыктан атларның күпчелек өлеше бөтенләй сафтан чыгарылган. Бу хәл Биектау районы җир бүлеге работникларына күптәннән инде билгеле. Ләкин алар бу хәлне төзәтү буенча һичбернинди конкрет чара күрмәгәннәр.

Бу уңай белән тик шуны гына әйтергә кирәк: язгы чәчүгә атларны яхшылап әзерләми торып язгы кыр эшләренең уңышлы үтәчәге турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Ат турында чын-чыннан, хуҗаларча кайгыртучанлык күрсәтелми икән, язгы чәчүгә әзерләнәм, дип әйтү мәгънәсезгә лыгырдау булачак.

Дөрес, бездә атларга карата үзләрендә тулы җаваплылык сизүче җитәкчеләр дә, билгеле, аз түгел. Безнең бурыч—барлык колхозларда да атларны язгы чәчүгә отлично итеп әзерләүне тәэмин итүдән гыйбарәт.

Язгы чәчүгә чыгарга санаулы гына көннәр калып бара. Атларны тәрбия итүне яхшыртырга, атлар турында һәрвакыт кайгыртучанлык күрсәтергә кирәк һәм шул ук вакытта мөгезле эре терлекләрне җигүле эшкә күнектерүгә җитди игътибар бирелергә тиеш.

Совет Информбюросыннан

28 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

28 нче мартта фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

21 нче марттан 27 сенә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 251 самолеты юк ителде. Шул ук вакытта без 95 самолет югалттык.

*27 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 5 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 2 тимер юл составын җимерделәр, 11 артиллерия һәм миномет батареясының утын бастырдылар.

*Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр аерым участокларда җирле әһәмияте булган сугышлар алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары бер урман участогын немецлардан чистарттылар. Бу участок өчен булган сугышларда дошманның бер ротага якын пехотасы юк ителде. 2 орудие, 6 пулемет, танкка каршы ата торган 3 мылтык, бер сугыш припаслары складлары һәм бер радиостанция кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең бер подразделениебез гитлерчыларны ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгарды һәм шул вакытта 100 дән артык немец солдатын һәм офицерын юк итте.

* Чугуевтан төньяктарак безнең подразделениеләр Төньяк Донецның сулъяк ярына үтәргә маташкан дошман ротасын юк иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Икенче бер участокта немецлар, Н-че часть урнашкан урынга үтеп кереп, авылның бер читен ала алганнар иде. Безнең сугышчылар, кискен контратака ясап, дошманны бу авылдан бәреп чыгардылар һәм элекке хәлне кайтардылар. 300 гә якын гитлерчылар, дошманның бер танкысы һәм бер самоход пушкасы юк ителде.

*Белгород районында күп кенә участокларда дошман разведка ясарга маташып карады. Безнең подразделениеләр җирле әһәмияте булган сугышларда 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташладылар һәм дошманның 2 бронемашинасын сафтан чыгардылар.

*Волынь өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды оккупантларга каршы сугышта 80 гитлерчыны юк иткән. Партизаннар немецлардан сугыш припаслары төялгән берничә олауны сугышып алганнар, 5 пулемет һәм 60 винтовка кулга төшергәннәр.

*Немецларның 13 нче пехота корпусы штабының разведка отрядыннан плен алынган өлкән тәрҗемәче, лейтенант Отто Зинскер болай диде: «Без үз корпусыбыз каршына урнашкан рус частьларының югалтулары һәм торышы турында ай саен ике тапкыр сводкалар төзи идек. Хәзер инде моны искә алу көлке һәм оят. Ләкин бу сводкаларда ун гына процент дөреслек булган булса да, сугыш инде күптән беткән булыр иде. Һәрбер офицер яки генерал, нинди булса да донесение китергән чакта, Гитлерга күңелсез булган һәм ул теләмәгән барлык нәрсәләрне сызып ташлый иде. Сызмаган кешенең муены сынарга мөмкин иде. Без үзебезне алдадык һәм моның өчен бик каты җәзаландык. Мәгълүм ки, руслар безнең оборона линиясен өзделәр. Корпус штабының һәм рухлары төшкән солдатларның калдыклары көнбатышка таба үтәргә маташтылар. Штаб карамагында 200 автомашина бар иде, ләкин аларны ташлап калдырырга туры килде. Барыбыз да җәяү бардык. Мин бер авылга кердем һәм плен бирелдем».

*Курск өлкәсенең Ивница авылында немец-фашист кабахәтләр коточкыч җинаятьләр эшләгәннәр. Чигенер алдыннан гитлерчылар бөтен халыкны үзләре белән алып китмәкче булганнар. Күп кешеләр яшеренгәннәр. Шуннан соң немецлар авылны яндырганнар һәм граждан халкын куып йөри башлаганнар. Солдатлар ирләрне, хатын-кызларны һәм балаларны базлардан өстерәп чыгарганнар. Немецлар колхозчы Антонина Дмитриеваны, аның 10 яшьлек кызын, колхозчы Людмила Кухтинаны, аның 3 кечкенә баласын, укытучы Надежда Кириченкованы, аның 2 баласын һәм 60 яшьлек анасын, укытучы Анна Слотинаны, аның кызын, укытучы Лидия Абросимованы, аның 3 яшьлек улын һәм башка кешеләрне терелэй яндырганнар. Калган авыл халкының күп өлешен немец бандитлар ирексезләп үзләре белән алып киткәннәр.

29 нчы МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

29 нчы мартта фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

* 28 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар, 5 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар.

Кара диңгездә безнең авиациябез дошманның 4.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырды.

* Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр аерым участокларда җирле әһәмияте булган сугышлар алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, аның бер терәк пунктын алдылар. Дошманның 160 солдаты һәм офицеры юк ителде. Гвардияче өлкән лейтенант Баландиннан, старшина Пустоваловтан һәм сержант Неймулиннан торган бер танк экипажы бу сугышта немецларның 3 танкысын сафтан чыгарды һәм дошманның бер миномет батареясын таптап үтте. Гвардияче кече лейтенант Туленковның танк экипажы немецларның 5 ДЗОТ ын, 4 орудиесен һәм берничә пулемет точкасын юк итте.

* Белый шәһәреннән көньяктарак дошманның көчле итеп ныгытылган каршылык күрсәтү узелына килә торган юлларда бик каты сугыш булды. Иптәш Кебардзе командалыгындагы частьның сугышчылары немецларга атака ясадылар һәм бер урында аларның оборонасына үтеп керделәр. Шул ук вакытта лейтенант Жилин, үзенең сугышчылар отряды белән, гитлерчыларның тылына барып чыкты һәм аларга кинәт һөҗүм итте. Аз гына сугышканнан соң немецлар гарнизонының шактый өлеше юк ителде. Немецлар, элекке хәлне кайтарырга теләп, ике тапкыр контратакага күчтеләр, ләкин үзләре өчен зур югалтулар белән алып ташландылар. Безнең подразделениеләр, дошманны хәлсезләндереп, алга киттеләр һәм халык яши торган тагын 3 пунктны алдылар.

* Белгород районында Н-че часть автоматчиклары кинәт дошманның бер батальон пехотасына һөҗүм иттеләр һәм аны таркаттылар. 100 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Икенче бер участокта безнең саперлар дошманның 3 зур ДЗОТ ын һәм аларның гарнизоннарын шартлаттылар.

* Төньяк Донецның урта агымы районында дошман елганың сулъяк ярына чыгарга маташты. Совет сугышчылары, барлык төр кораллардан атып, немецларны таркаттылар. Дошманның 200 гә якын солдат һәм офицерлары кырып ташланды, 4 минометы, 2 орудиесе һәм берничә автомашинасы юк ителде. Совет снайперлары уңышлы хәрәкәт итәләр. Кызылармеец иптәш Колосов 5 нче марттан 28 енә кадәр 40 гитлерчыны юк итте. Сугышчы иптәш Гришин бер көн эчендә 4 немецны үтерде.

* Смоленск партизаннарының бер отряды төнлә белән немецларның бер гарнизонына һөҗүм иткән һәм 45 немец солдатын һәм офицерын кырып ташлаган. 2 пулемет һәм 35 винтовка кулга төшерелгән. Шул ук төнне икенче бер партизаннар отряды немец-фашист илбасарлар тукталган бер авылны чолгап алган. Партизаннар берничә дистә гитлерчыны юк иткәннәр.

* Түбәндә Ростов өлкәсенең Тарасовка районында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Тарасовка районының немецлар аягы баскан һәрбер станицасында аларның канлы җинаятьләренең эзе калды. Бандитлар гөрләп торган колхозларны җимерделәр, колхозчыларның милекләрен таладылар. Чигенер алдыннан фашист ерткычлар бер төн эчендә Тарасовкадагы бөртекле ашлык совхозында 143 кешене газапладылар һәм аттылар. Атылганнар арасында тракторчы Иван Свитенко, аның хатыны һәм ике баласы, көтүче Семен Шадько, слесарь Николай Медведев, аның хатыны һәм улы, укытучы Вера Крепокова, тракторчы Любовь Мановицкая һәм башкалар бар. Безнең районда гитлерчы варварлар эшләгән барлык җинаятьләрне бер актта гына санап бетерергә мөмкин түгел. Тарасовка станицасында торучылар немецлар тарафыннан нахакка коелган кан өчен үч алырга һәм гитлерчы бандитлар шайкасын тар-мар итү өчен үзләренең барлык көчләрен бирергә ант иттеләр». Актка Н. Слепченко, П. Гусаров, М. Хәлимов, С. Владыкин, А. Пристенская, М. Дунаев, Н. Пименова, М. Погребняк, Т. Приходченко һәм башкалар кул куйган.

ФИННАРНЫҢ ДИВЕРСИЯ ГРУППАСЫ ТАР-МАР ИТЕЛДЕ

Карелия фронты, 23 март. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Финнарның зур бер диверсия отряды, каткан сазлыклар аша фронт линиясен үтеп, безнең тылдагы коммуникацияләрнең берсенә килеп чыкты. Финнар, вак группаларга бүленеп, берничә поселокта урнашкан совет гарнизоннарына һөҗүм иттеләр.

Башланып киткән сугышларда финнар берниндн дә уңышка ирешә алмадылар. Шул арада тревога буенча килеп җиткән совет частьлары диверсантларны чолгап алдылар, һәм финнар, җитди куркыныч туганлыкны сизеп, урманга китәргә маташтылар, ләкин качып котыла алмадылар.

Диверсантларның аерым группалары белән сугыш ике көн дәвам итте. 120 дән артык фин солдатлары һәм офицерлары юк ителде, зур группа финнар плен алынды.

П. БАРАННИКОВ.

Ватан сугышы һәм тоталь сугыш

М. И. КАЛИНИН

* * *

Караңгы төн уртасында Германия армиясе безнең илебезгә кинәт бәреп керде. Совет хөкүмәте хәлнең бөтен тирәнлеген шунда ук аңлады һәм сугышның беренче көненнән үк Советлар Союзы халыкларын агрессорга каршы ватан сугышына чакырды.

Гитлер Германиясе дөньяга яңа сугыш такты. Бу сугышны ул тоталь сугыш дип атый һәм бу сугыш турында немец генераллары, зур һәм кече фюрерлар, махсус хәрби әдәбиятта да, гомуми әдәбиятта да бик күп лыгырдыйлар.

Фашистик тоталь сугышның мәгънәсе нәрсәдә соң? Бу сугыш турындагы идея Германия империализмының басып алу омтылышлары нигезендә үсеп чыкты һәм ул немец плутократларының шөһрәт сөюдә туган ниятләрен бөтен нәрсәдән дә тулырак чагылдыра. Гитлерчы фашизм Германиянең үтә ерткыч империалистларына политик таяныч, ә Гитлер йөзендә башлык та бирде. Германия империалистлары үзләренең агрессорлык ниятләрен тормышка ашыру өчен иске средстволар җитәрлек түгел дип һәм бары тик тоталь сугышның канлы юлы гына аларны бөтен дөнья күләмендә хакимлеккә китерер дип исәплиләр.

Гитлер Германиясе хәзерге сугышта Кайзер Германиясе тормышка ашырырга маташкан максатларга караганда киңрәк һәм агрессиврак максатларны үз алдына куйды. Әгәр дә узган сугышта Германия империализмы читләр территорияләрен басып алырга һәм аларны үзенә буйсындырырга омтылган булса, бөтен дөнья базарында күп кенә уңайлы позицияләр алуны үзенең бурычы итеп куйган булса, Гитлер Германиясе, шуның белән бер үк вакытта, бөтен бер халыкларны физик кырып бетерү, аларның дәүләтчелеген, аларның милли культураларын юк итүне дә үз алдына бурыч итеп куя.

Немец сугыш чукмарларының фикеренчә тоталь сугыш башта ук илнең барлык материаль ресурсларын һәм кеше резервларын максималь дәрәҗәдә файдаланып алып барылырга тиеш. Ул дошманны тар-мар итү өчен иң күп төрле средстволарны һәм методларны файдалануны эченә ала. Моңа түбәндәгеләр керә: Германия фашизмының яраткан методы—бөтен дөнья күләмендә шантаж, тынычлыкка һәм дуслыкка омтылудагы ышандырулар белән күрше халыкларның хәрби сизгерлеген томалау, ә аннары аларга көтмәгәндә һөҗүм итү, ялган, алдау һәм яла ягу; Германия армиясенең, имеш, искиткеч куәтлелеге һәм аның коралының өстенлеге турында шапрынулы пропаганда; ниндидер аеруча һәм беркем тарафыннан да күрелмәгән сугыш средстволарына ия булу турында серле итеп сөйләнүләр; һәртөрле куркыту средстволары куллану; шәһәрләрне җимерү, авылларны яндыру, гражданнар халкын күпләп үтерү, күп кенә ирләрне, хатыннарны, кызларны, үсмерләрне Германиягә каторга эшенә куып алып китү; барлык оккупацияләнгән территориянең халкына үзләренең хакимлекләре белән дәһшәт салу һәм шуның белән халыкларның каршылык күрсәтүгә омтылышын богауларга маташу. Дошманга үзенең резервларын җыярга мөмкинлек бирмәү, аның хәрби көчләрен кинәт җимерү, аның мораль хәлен һәм каршылык күрсәтүгә омтылышын бастыру, аның материаль базасын җимерү һәм юк итү теләге белән сугыш һөҗүме һөҗүм итүче як өчен аеруча уңышлы шартларда тормышка ашырыла. Немецларның тоталь сугышының аерымлыклары шундыйлар.

Польша, Голландия, Бельгия һәм Франция халыклары тоталь сугышның аерымлыкларын үз күзләре белән күрделәр. Ләкин гитлерчы кеше ашаучылар моны Советлар Союзына каршы аеруча кискенлек белән тормышка ашыралар. Алар кыргыйларча ләззәтләнү белән йөзләрчә мең ярдәмчесез совет кешеләрен үтерәләр, материаль һәм культура кыйммәтләрен юк итәләр. Һәм бу йөгәнсезләндерелгән фашистик урдаларның юлбасарлык исереклеге белән түгел, бәлки югарыдан төгәл билгеләнгән, сугыш башланганчыга кадәр күп вакытлар алдан эшләнгән төгәл план буенча башкарыла.

Гитлерчылар шайкасы тарафыннан тормышка ашырыла торган тоталь сугышның бу формалары һәм методлары үзеннән-үзе узган замандагы сугышларга—Азиядә Чыңгыз хан һәм Русьта Батый сугышларына тарихи чагыштырманы сорыйлар. Немецлар, сугыш техникасының югары үскән хәзерге үзгәргән шартларында басып алучыларның сугыштагы бу методларын тормышка ашырып, үзләренең хәрәкәтләре белән аларны кабатлагандай булып күренәләр.

Ләкин бу, әйтергә кирәк, бары тик тышкы охшау гына. Батыйның һөҗүме моннан җиде йөз ел элек булды. Дөрес, ул, варварларча һөҗүм иде, ләкин шулай да немецлар пропагандалый һәм үткәрә торган тоталь сугыш кебек үк үтә ерткыч характерда булмады. Монда, һичшиксез, фашистлар беренче урында торалар. Узган гасырлар эчендә фән бик нык алга китте һәм, немецлар кешеләрне нечкәлек белән җәзалау һәм газаплау өчен аны тулысынча файдаланалар.

Гитлерчы урдалар безнең җиребездә сугыш хәрәкәтләрен Кызыл Армиягә каршы гына түгел, бәлки барлык совет халкына каршы да алып баралар. Фашистик командование оккупацияләнгән совет районнарында тыныч халыкның шактый өлешен физик юк итүнең алдан уйланган киң системасын тормышка ашыра. Гитлерчы хәрби начальниклар һәм гражданнар властьлары чыгарган бик күп документаль материаллар, хәзерге заман каннибалларының халыкны план буенча юк итүгә, аның милли культурасын, уку йортларын бетерүгә, тарихи памятникларны юк итүгә, музейларны һәм китапханәләрне талауга, бер сүз белән әйткәндә, тарихи формалашкан милләтнең бөтен рухани кыйммәтен тәшкил итә торган барлык нәрсәне юк итүгә юнәлгән методларын тулысынча ачып салалар.

Мәсхәрәләүләр, газаплаулар, масса күләмендә үтерүләр сугыш барышының һәркөне үткән саен зуррак күләмнәргә керә баралар, теләсә нинди халыкның тарихи үткәнендә булган иң зур дәһшәтләрдән дә узып китәләр. Болар барысы да бер максатка—кол ителгән халыкны таркатуга, аның көрәшкә омтылышын юк итүгә, шулай чистартылган фонда үзләренең фашистик кабахәтлекләрен иркенләп башкаруга юнәлдерелгән. Немец фашистлары сугышны тоталь сугыш дип атыйлар, ә чынлыкта бу просто фашистик бандитларның Европа олы юлындагы юлбасарлыклары гына.

Советлар Союзында немецлар эшләгәннәрнең барысы да, тоталь сугыш планы буенча, алар оккупацияләгән башка Европа илләрендә дә шул ук дәрәҗәдә үткәрелергә тиеш иде. Ә моны тулысынча үткәрүгә немецларга Совет—Германия фронты комачаулый. Шулай да мөмкин булуга карап, алар Европа халыкларын кол итү буенча үз планнарын һәр урында тормышка ашыралар. Немец фашизмының, мәсәлән, немец алпавытлары һәм кулаклары массасын көнчыгышка күчерү өчен Польша милләтен эзлекле рәвештә бетерү политикасы алып барганлыгын бары тик аңлы рәвештә күз йомучы кешеләрнең генә күрмәүләре мөмкин.

Голландия, мәсәлән, немецлар өчен күзгә төшкән ак кебек булып тора, чөнки ул Германиягә диңгез яры буйларын Англиягә каршы файдаланууга комачаулый. Шунлыктан фашистик хөкүмәтнең голландиялеләргә Украинага күчеп утырырга «киңәш» итүе, алар урынына сайлап алынган немецларны урнаштырырга, шулай итеп Англиягә каршы алдынгы бастион булдырырга теләве очраклы түгел. Шул ук вакытта немец-фашист басып алучылар голландиялеләрне немецлар урынына Украина партизаннары пуласы астына куярга телиләр.

Әгәр дә фашистик хөкүмәтнең политикасына, аның сугыш методларына, оккупацияләнгән илләрне идарә итү ысулларына анализ ясап карасаң, ул вакытта фашистларның бөтен эшләгән эшләре аларның җәһәннәм планыннан килеп чыга. Бу планның мәгънәсе шундый: эшчеләрнең һәм крестьяннарның актив өлешен үтереп бетерү, Европа илләрендәге интеллигенцияне суеп бетерү, халыкның бирешерлек өлешен немецлаштыру, җиңелгән халыкларны кол итү. Бу фантастика гына, дип әйтүләре мөмкин. Әгәр дә немецлар җиңсәләр? Алар бу планны Советлар Союзының оккупацияләнгән районнарында үткәргән кебек үк һәр җирдә дә үткәрерләр иде. Бу бәхәссез.

Гитлерның тоталь сугышына совет халкы бөек ватан сугышы белән, ватанны канлы агрессордан саклау хакына гадел сугыш белән җавап бирде. Советлар Союзының һәрбер гражданины үзенә генә түгел, бәлки аның семьясына да, бездә урнашкан бөтен тормыш укладына да куркыныч туганлыкны тирәнтен аңлый. Һәм совет халкының юлбашчысы безнең илебезнең барлык гражданнарын ватан сугышына, ягъни бөтен халык сугышына, халыкта булган барлык средстволар белән сугышуга чакырды.

Иптәш Сталин 1941 нче елның 3 нче июлендә радио аша сөйләгән речендә халкыбызга болай дип аңлатты: «Фашистлар Германиясенә каршы сугышны гадәттәге сугыш дип кенә санарга ярамый. Ул ике армия арасындагы сугыш кына түгел. Шуның белән бергә ул немец-фашист гаскәрләренә каршы бөтен совет халкының бөек сугышы».

Иптәш Сталин совет кешеләрен дошман басып алган районнарда, дошман армиясе частьларына каршы көрәшү өчен, һәркайда һәм һәр урында партизаннар көрәшен кабызып җибәрү өчен, күперләрне, юлларны шартлату өчен, телефон һәм телеграф челтәрен бозу өчен, урманнарны, складларны, обозларны яндыру өчен партизаннар отрядлары һәм диверсия группалары төзәргә чакырды. «Басып алынган районнарда дошман өчен һәм аның барлык ярдәмчеләре өчен түзәргә мөмкин булмаслык шартлар тудырырга, аларны һәрбер адымда эзәрлекләргә һәм юк итәргә, аларның барлык чараларын өзәргә кирәк».

Немецлар алган территорияләрдә совет гражданнарының хәрәкәтләре турында иптәш Сталинның бу практик күрсәтмәләре ватан сугышының формаларын ачып күрсәтәләр, аңа хас булган аерымлыкларны билгелиләр. Бу—безнең һәрбер кешебез,—ирләр дә, шулай ук хатын-кызлар да,—дошманга ударны һәркайда һәм һәр урында ясауны үз фикерләренең һәм хәрәкәтләренең төп максаты итеп куярга тиеш.

Ватан сугышында, дошманга каршы турыдан-туры көрәштә халык катнашының партизаннар хәрәкәте кебек формасы үзе үк бөтен халык сугышы билгесе булып тора. Бары тик үз ватанының азатлыгы һәм бәйсезлеге аның өчен тормышта иң кыйммәтле нәрсә дип исәпләгән халыкның гына оккупантларга каршы көрәштә шул кадәр батырлык, кыюлык һәм үз-үзен аямаучан геройлык күрсәтүе мөмкин

Безнең шәһәр һәм авыл халкыбызның милли ныклыгын һәм бөек патриотизмын, немец фашизмына тирәнтен дошманлыгын һәм килешмәүчәнлеген фашистик башлыклар үз җилкәләрендә татып ышандылар. Немец басып алучылар үзләренә каршы совет кешеләренең бу дошманлык хисләрен бетерергә никадәр генә маташсалар да, алар моңа беркайчан ирешә алмаячаклар. Торган саен үсеп баручы партизаннар көрәше оккупацияләнгән территориядә дошманга маневр ясау иркенлеген бирми һәм аны экономик үзләштерү өчен җиңелмәслек киртә булып тора. Буйсынган халыкның булмавы оккупация армиясен авыр хәлгә куя. Оккупацияләнгән районнарның халыкларын сөйләшми торган колларга әверелдерү өчен көрәштә дошманның югалтулары арта. Безнең халкыбыз торган саен килешмәүчәнрәк булып әверелә, немец басып алучыларга каршы кулына корал тотып торган саен катырак сугыша.

Советлар Союзы халыклары үзләренең изге сугышларында, совет ватанына карата мәхәббәт һәм патриотик бурыч тойгысы белән тулган хәлдә, үзләренең азатлыклары һәм бәйсезлекләре өчен көрәшкә бөтен көчләрен аямыйча бирәләр. Советлар Союзы азатлык өчен халык сугышы алып бара. Совет кешеләренең фронтта да һәм тылда да үз-үзләрен аямаулары һәм бөек патриотизмы бу сугышның чыннан да халыкчылыгы турында сөйли. Хәзер һәрбер совет гражданины немец фашистларына каршы көрәшкә үзенең барлык көчен, сәләтләрен һәм средстволарын бирергә тиешлеген аңлый дип кыю рәвештә әйтергә мөмкин. Советлар Союзы халыклары бөек ватан сугышында үзләренең бу бөек хисләрен күп санлы үрнәкләр белән демонстрацияләлиләр.

Танк колонналары һәм самолетлар эскадрильялары төзүгә средство туплау кампаниясе совет патриотизмының аеруча ачык күренеше булып тора. Бу кампания колхозчылар инициативасы белән башланды һәм аннары эшчеләр һәм интеллигенция тарафыннан күтәреп алынды. Һәм безнең крестьяннар, эшчеләр, интеллигенция, хезмәткәрләр берике ай эчендә ирекле рәвештә берничә миллиард сум акча җыйдылар. Немец басып алучыларга каршы сугышны безнең халкыбыз халык сугышы дип саный. Һәм бу табигый. Чөнки немец-фашизмы Кызыл Армиягә каршы гына түгел, бәлки бөтен халыкка каршы да сугыша, аның актив өлешен кырып бетерергә, ә калганын — кол итәргә тели.

Ватан сугышы совет халкында чиксез күтәренкелек тудырды, аның әле тулысынча күренеп бетмәгән көчләрен уятты. Безнең халкыбыз сугышның бу айлары эчендә барлык өлкәләрдә — хәрби, промышленность, авыл хуҗалыгы өлкәләрендә—гаять зур санда уйлап табулар бирде. Иң катлаулы заданиеләр дә гаҗәеп кыска срокларда үтәләләр. Безнең халкыбыз, явыз дошманны тизрәк җиңү өчен материаль кыйммәтләрен һәм хезмәтен генә түгел, бәлки үзенең барлык иҗади көчләрен дә бирә.

Иптәш Сталинның фронттагы, тылдагы һәм дошман тарафыннан вакытлыча алынган территориядәге совет кешеләренә карата чакыруының нәтиҗәлелеге бу сугышның безнең өчен халык сугышы, ватан сугышы икәнлеге турында барыннан да яхшырак сөйли. Немецлар командованиесе фронтта нинди генә трюклар ясаса да, гитлерчы хөкүмәт ничек кенә көчәнсә дә, немец фашист урдалары тар-мар ителәчәк һәм безнең җиребездән хурлык белән куылачак.

Ватан сугышы хәзерге моментта барлык совет халкының төп, ихтимал, бердән-бер максаты булып тора, һәм бу бөек гадел сугышта ул җиңәр.



Сталинград бүген. Рәсемдә: Сталинград ГРЭС ында төзекләндерү эшләре алып барыла.

ТАСС фотохроникасы.

„Советлар Татарстаны" сугышчан сафларда

ОРДЕНЛЫ ТАТАРСТАН ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ СУГЫШ САМОЛЕТЛАРЫ ЭСКАДРИЛЬЯСЫН Н-ЧЕ ЧАСТЬКА ТАПШЫРДЫ

Н-че аэродромда unкарча сугыш машиналары тезелгән. Һәрбер машинаның фюзеляжына «Советлар Татарстаны» дип язылган. Эшчеләр, хезмәткәрләр, колхозчылар, совет интеллигенциясе, Татарстанның барлык хезмәт ияләре бу куәтле һава корабльләрен төзү өчен үзләренең саклык акчаларын бирделәр.

Бу сугыш машиналарын Кызыл Армиягә тапшыру өчен Татарстан хезмәт ияләре делегациясе—алдынгы промышленность предприятиеләренең һәм колхозларның стахановчылары килделәр. Очу мәйданында Н-че частьның очучылары тезелделәр. Митингны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе иптәш Динмөхәммәтов ачты.

Татарстанның эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре исеменнән Н-че заводның цех начальнигы иптәш Гордин чыгып сөйләде. Ул болай диде:

—Татарстанның хезмәт ияләре бу сугыш корабльләрен сезнең кулыгызга зур шатлык белән тапшыралар һәм дошманны тар-мар итү өчен бу машиналарның дәһшәтле корал булачагына, ватаныбызны немец илбасарлардан азат итү өчен аларның ярдәм күрсәтәчәгенә чын күңелдән ышаналар.

Кызыл Армия сугышчылары һәм командирлары исеменнән Лозенко, Нечипоренко һәм Галиәхметова иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Иптәш Нечипоренко Татарстан хезмәт ияләренә Кызыл Армиянең чын күңелдән рәхмәтен тапшыра һәм болай ди:

— Бу сугыш машиналарын алып, без сезне ышандырабыз: сезнең ышанычыгызны акларбыз, партия һәм хөкүмәт тарафыннан безгә йөкләнгән сугышчан бурычларны уңышлы итеп үтәрбез. Яшәсен бөек полководец, Верховный Баш Командующий, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталин!

Митингтан соң делегация членнары самолетларның экипажларына машиналарның формулярларын тапшырдылар.

Н. ШӘҺӘРЕ.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ КЕРЕШЕР КӨННӘР ҖИТӘ.

ҺӘРБЕР КОЛХОЗДА, ҺӘРБЕР СОВХОЗДА ҺӘМ МТС ТА, ҺӘРБЕР БРИГАДА ҺӘМ ЗВЕНОДА ӘЗЕРЛЕКНЕҢ ТОРЫШЫН ҖЕНТЕКЛӘП ТИКШЕРЕРГӘ, КИМЧЕЛЕКЛӘР ТАБЫЛА ИКӘН, КИЧЕКМӘСТӘН БЕТЕРЕРГӘ.

☆ ☆

Колхозларның ОРЛЫК ФОНДЫНА

Совет патриотларының взносы

91. **Кәлимуллина Н.** — Азнакай районы, «Житез» колхозы члены—60 пот ашлык бирде.

92. **Абдуллин Р.** Азнакай районы, «Житез» колхозы члены—54 пот ашлык бирде.

93. **Зарипов Я.**—Азнакай районы, «Житез» колхозы члены—30 пот ашлык бирде.

94. **Вахитов** — Азнакай районы, «Зирекле елга» колхозы члены—48 пот ашлык бирде.

95. **Солтанова**—Азнакай районы, «Зирекле елга» колхозы члены, фронтовик хатыны—48 пот ашлык бирде.

96. **Хәсәнова З.**—Әтнә районы, «Электросталь» колхозы члены—20 пот ашлык бирде.

97. **Абдуллина З.**—Әтнә районы, «Электросталь» колхозы члены—10 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

98. **Хәбибуллина Ә.**—Әтнә районы, «Электросталь» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 5 пот бәрәңге бирде.

99. **Шакиров Б.**—Әтнә районы, Каганович исемендәге колхоз члены—12 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

100. **Рәкыйпов В.**—Әтнә районы, «Ирек» колхозы члены—12 пот ашлык, 5 пот бәрәңге бирде.

101. **Баһавиев Х.**—Әтнә районы, «Ирек» колхозы члены—12 пот ашлык һәм 30 пот бәрәңге бирде.

102. **Вәлиуллина Ү.**—Әтнә районы, Куйбышев исемендәге колхоз члены—41 пот ашлык бирде.

103. **Хәсәнова С.**—Актаныш районы, «Изаил» колхозы члены—фронтовик хатыны—31 пот ашлык бирде.

104. **Мукимова Х.** — Актаныш районы, «Изаил» колхозы члены—25 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

105. **Хәсәнова Г.** — Актаныш районы, «Изаил» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

БЕР ГЕНӘ ГЕКТАР ҖИРНЕ ДӘ ЧӘЧМИ КАЛДЫРМАБЫЗ

ЧИРМЕШӘН, 29 март. (Телефон буенча). Беренче Май районының барлык колхозларында да язгы чәчүгә ныклы әзерлек бара. Хәзер 12 колхозда язгы чәчүне уңышлы үткәрү өчен кирәкле бөтен нәрсә әзер. 1943 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләрен үткәрү буенча дәүләт планы турында ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының карары колхозчылар арасында эшкә булган активлыкны тагын да үстерде. Бу планны уңышлы тормышка ашыру өчен, беренче чиратта язгы чәчүгә әзерлек эшендә булган барлык житешсезлекләрне кичекмәстән бетерү, житешмәгән чәчү орлыгын урында табу төп бурыч итеп куелды. Шушы мәсьәлә буенча колхозчылар арасында масса-аңлату эшләре җәеп җибәрелде.

Колхозларның һәм колхозчыларның үзләреннән арткан ашлыкларын бурычка биреп тору тәртибендә районда 10.000 потка якын ашлык, 20.000 потлап бәрәңге җыйналды. «Красное знамя» колхозы үзеннән арткан ашлыктан чәчү орлыгы житмәгән башка колхозларга 500 пот ашлык, 250 пот бәрәңге бирде. Шушы колхозның членнары П. Фролов һәм В. Гришанин иптәшләр 36 шар пот, А. Фролов, Островский, А. Дуглов иптәшләр 30 ар пот ашлык һәм 6 шар пот бәрәңге бурычка биреп торалар.

Колхозара ярдәмләшү тәртибендә «Кызыл нур» колхозы 450 пот ашлык, 850 пот бәрәңге, Куйбышев исемендәге колхоз 400 потка якын ашлык, 246 пот бәрәңге, Ворошилов исемендәге колхоз 378 пот ашлык, 250 пот бәрәңге бирде.

Колхозчылар да үз хуҗалыкларындагы ашлыктан колхозларга бурычка чәчү орлыгы биреп торуда зур активлык күрсәтәләр. «Радио» колхозы членнарыннан иптәш Ф. Башарина 96 пот ашлык, Варвара Васильева һәм Митрофан Харитонов иптәшләр 60 шар пот ашлык, «Красная роща» колхозы члены Елизавета Сотникова 60 пот ашлык, 36 пот бәрәңге, Ворошилов исемендәге колхоз члены иптәш П. Антонов 30 пот ашлык, 20 пот бәрәңге, С. Гаврилов 24 пот ашлык бирделәр.

Илгә һәм фронтка һәръяклап ярдәм итүче мондый колхозчыларны күпләп санарга мөмкин. Аларның бу активлыгын тагын да үстереп, районда язгы чәчүне яхшы әзерлек белән каршылау һәм аны үрнәк төстә үткәрү өчен көрәшәбез.

ШӘРИП ДӘҮЛӘТШИН,
Район советы башкарма комитеты председателе.

АКАДЕМИК ЛЫСЕНКО МЕТОДЫ

Арча районының орлык тикшерү лабораториясе академик Лысенконың яңа методын куллану буенча киң эш җәелдерде. Лабораториядә беренче тикшерү вакытында түбән тишелеш биргән орлыклар да яңа метод белән эшләгәндә шактый яхшы нәтиҗә бирделәр.

Түбән Чокырча авылы, Ленин исемендәге колхозның 141 центнер арпасы беренче тикшерү вакытында 44 процент кына тишелеш биргән иде. Лаборатория арпаны яңа метод белән тишелдереп карады. Анализ өчен алынган орлыкны бер тәүлек суга салып торгач, һәрбер орлыкның ярысын иңә белән тишеп чыгылды һәм сынау ящикларына утыртылды. Нәтиҗәдә орлыкның тишелеп чыгу сәләтенең артуы һәм арпаның 94 процентлы кондициядә икәнлеге билгеле булды. Димәк, академик Лысенко күрсәткәнчә, ул вакытта бу арпа тынычлык дәвере үткәргән булган.

«Көрәш Курса» колхозының 80 центнер арпасы беренче анализ вакытында 68 процент, «Ирек» колхозының 9 центнер арпасы 53 процент, Утар аты колхозының 140 центнер бодае 69 процент кына тишелеш биргәннәр иде. Икенче кат тикшергәннән соң, аларда да 95 проценттан алып, 99 процентка кадәр тишелү сәләте булганлыгы беленде.

Хәзер райондагы барлык колхозлар да лабораториядән анализ документлары алдылар. Алар академик Лысенко методы белән анализ ясалган орлыкларны чәчүгә әзерләү белән шөгыльләнергә тиешләр, чөнки ул орлыкларның чәчү вакытында тынычлык дәверендә булулары мөмкин. Аларны бу дәвердән уяту чараларын күрергә кирәк. Агрономия мондый орлыкларны юка катлауларга җәеп таратырга, яхшылап болгата-болгата җиллэтергә, һава алдырырга киңәш бирә.

НУР ХӘЙРУЛЛИН.

ПАТРИОТКА ХИКМИЕВА ҮРНӘГЕНДӘ

«Яңа юл» колхозында (Минзәлә районы) язгы чәчүгә орлык туплау декадасы яхшы нәтиҗәләр бирде. Колхозыбызның чын патриоткасы Хикмиева һәм стахановчы карт Шәйхетдинов иптәшләрнең инициативасына авылыбызның күп кешеләре кушылдылар.

Колхоз членнарының булышлыгы аркасында, орлык фонды арткаҥнан арта барды. Хөснетдинов 52 пот, Сафина һәм Габитов иптәшләр 42 шәр пот, Гыйлаҗов, Хәмидуллин һәм Нуретдинов иптәшләр 36 шар пот ашлык биреп, орлык фондын баеттылар.

Шушындый зур взнослар белән орлык туплауга барысы 42 колхозчы катнашты, һәм тиз арада чәчүлек өчен 1.266 пот ашлык тупланды.

З. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 25 нче МАРТЫНА)

(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0	56. Яңа Чишмә	78,4
2. Чокалы	100,0	57. Рождественский	78,1
3. Актаныш	100,0	58. Шөгер	77,4
4. Бөгелмә	100,0	59. Мәлки	76,0
5. Нөркәй	100,0	60. Буа	75,9
6. Алга	100,0	61. Кәкре елга	75,4
7. Тымытык	100,0	62. Әхмәмәт	74,5
8. Алабуга	100,0	63 Беренче Май	74,5
9. Тирсә	100,0	64. Әтнә	74,0
10. Ишеево	100,0	65. Теләче	73,5
11. Чүпрәле	100,0	66. Солтан	73,5
12. Дөбьяз	100,0	67. Балык бистәсе	73,3
13. Яңиль	100,0	68. Кама тамагы	73,3
14. Олы Кариле	100,0	69. Зирекле	73,1
15. Юдино	100,0	70. Буденный	71,9
16. Юртыш	100,0	71. Салман	71,1
17. Исәнбай	100,0	72. Әлмәт	70,8
18. Т. Тамак	100,0	73. Столбище	70,4
19. Мөрәле	100,0	74. Питрәч	70,2
20. Зөя	100,0	75. Тәкәнеш	69,8
21. Поповка	100,0	76. Казанбаш	69,7
22. Чистай	98,0	77. Әлки	69,6
23. Кадряк	97,3	78. Маткавыш	69,0
24. Октябрь	96,6	79. Мөслим (Чистай)	67,7
25. Саба	96,5	80. Майдан	65,5
26. Дәүләки	95,7	81. Константиновка	65,4
27. Кичү	95,2	82. Черемуховский	64,8
28. Норлат	95,2	83. Морт	65,7
29. Чүрибураш	89,4	84. Кызыл юл	64,4
30. Чыбыклы	88,9	85. Биләр	63,5
31. Сарман	88,7	86. Каргалы	63,3
32. Заинский	87,9	87. Ромадан	63,0
33. Кузайкино	87,3	88. Алексеевский	63,0
34. Тархан	86,9	89. Арча	62,8
35. Б. Матак	86,3	90. Тат. Ходяш	62,5
36. Соколка	86,3	91. Макыл	62,3
37. Акташ	86,2	92. Чиябаш	61,9
38. Чаллы	85,5	93. Карамалы	61,8
39. Баулы	85,2	94. Иске Тимошкино	61,4
40. Кызыл йолдыз	84,7	95. Кошкино	60,9
41. Куйбышев	84,2	96. Минзәлә	60,9
42. Иске Тимошкино	84,2	97. Чишмә	60,6
43. Ютазы	84,0	98. Трехозерский	60,4
44. Чалпы	83,8	99. Мамадыш	59,7
45. Азин	83,3	100. Тат. Ялтан	59,1
46. Димитров	82,9	101. Үзәк	58,8
47. Бондюг	82,2	102. Иске Писмән	56,7
48. Аксубай	82,1	103. Зур Поляна	56,1
49. Кызыл Чапчак	82,1	104. Кузнечиха	52,4
50. Кукмара	82,1	105. Ключи	48,3
51. Калинин	82,0	106. Биектау	43,7
52. Тельман	80,3		
53. Тәтеш	79,2	Барлыгы:	78,8
54. Балтач	78,8	1943 нче елның 20 нче мартына	77,1
55. Әлшә	78,6		

РЕМОНТНЫ ТИЗРӘК ТӨГӘЛЛӘРГӘ

Язгы чәчүгә әзерлекне яхшы оештырган, ремонтта эшләүчеләр өчен кирәкле шартлар тудырган колхозларда авыл хуҗалыгы инвентарьларын ремонтлау төгәлләнде инде. Вахитов исемендәге колхозның тимерчесе иптәш Хәбибуллин авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтны Октябрь революциясенең 25 еллыгы көненә үк төгәлләде. Ул 48 сабан, 9 чәчү машинасы, 60 тырма һәм 24 культиваторны бик яхшы итеп төзәтте. «Индустрия» колхозының тимерчесе иптәш Коновалов та үз колхозларында ремонтны тәмамлаганнан соң, «Строитель» колхозына 8 сабан төзәтеп бирде. Хәзер ул биредә чәчү машиналарын ремонтлый. Гомумән иптәш Коновалов 7 колхозга хезмәт күрсәтә һәм һәркайсысында яхшы хуҗаларча кайгырта, теләсә нинди тимер кисәкләреннән кирәкле частьларны ясый һәм алардан бик оста файдалана белә.

Мондый тырыш тимерчеләр безнең районда шактый. Алар күрше колхозларга да тимерчелек эшендә ярдәм итү инициативасын күтәрделәр. Ләкин шушындый яхшы инициативаны җәелдерүдә район җир бүлеге мөдире иптәш Панов һәм аның работниклары колхозларга практик булышлык күрсәтмәделәр. Дөрес, ремонтны төгәлләгән колхозларның тимерчеләрен башка колхозларга беркетү турында карар чыгарылды. Ләкин бу карар урыннарга барып җитмәде, кәгазьдә генә калды. Мәсәлән, Служило-Шенталы авылы советына караган колхозлар Вахитов исемендәге авыл хуҗалыгы артеленә беркетелгәннәр иде. Карар чыкканга 2 айдан артык вакыт үтте инде. Бу авыл советына караган колхозларда эшнең яхшырганы юк әле. Вахитов исемендәге колхозның тимерчеләренә күрше колхозларга ярдәм итү турында хәбәр дә ителмәгән.

Менә бу хәл иптәш Пановның чыгарылган карарларның үтәлешен тикшермәгәнлеген һәм колхозларга практик булышлык оештырмавын күрсәтә. «Красная Шенталка» колхозында ремонт әле дә башланмаган. Сабаннар һәм тырмаларның күбесе кар астында калганнар. Ләкин район җир бүлеге работникларының бу эшкә бер дә исләре китми. Алар бу колхозга барып, аңа урында ярдәм оештыру турында карар чыгарып кына калдылар. Иптәш Пановның Служило-Шенталы авыл советына караган колхозларның берсендә дә булганы юк.

Районда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтның күрсәткечләре бик түбән. Сабаннарның 75 проценты, чәчкечләрнең 68 проценты, тырмаларның 86 проценты, культиваторларның 83 проценты гына ремонтланган әле. Ремонтның темпы соңгы көннәрдә бөтенләй акрынайды. Сабаннарны төзәтү дәрәҗәсе 10 нчы марттан 15 нче мартка кадәр, 5 көн эчендә бары 3 процентка гына күтәрелгән. Башка төр авыл хуҗалыгы инвентарьларын төзәтүдә 5—6 процентка гына арткан.

Ремонтның кайбер вак мәсьәләләренә тукталганда хәл тагын да кызганычрак. Сабаннарны да ал төрәннәр белән тәэмин итәргә, валеклар, постромкалар, сабан ачкычлары һәм кирәкләрнең җитәрлек булуы кирәк иде. Ләкин бу эшләрнең ни дәрәҗәдә икәнен район җир бүлеге җитәкчеләре бөтенләй белмиләр. Язгы чәчүгә әзерлекнең торышын һәм сыйфатын тикшерү үз көнлегендә бу җитешсезлекләрне бетерү чаралары күрелергә тиеш.

К. СЛЕПНЕВ.

„ЭРДЖИКИНЭЗ“

ТЕАТР

(В. БРАГИН ӘСӘРЕ. ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ ПОСТАНОВКАСЫ)

Тау халыкларының вәкиле, ингуш, ашуг Сөләйман, кулларын җәеп, кочакларга омтылгандай булып Серго Орджоникидзегә таба атлый. Ул бары тик аның исемен әйтергә генә килгән.

— Минем исемемне әйтергә?— дип башта гаҗәпләнә Серго.

Әйе, ул аның исемен генә әйтә. Ләкин, тау халыклары тарафыннан Сергога кушылган бу исем ничаклы күп һәм тирән мәгънәле итеп сөйли!

— Эрджикинэз, ягъни ярлылар князе!

Ашуг Сөләйман, барлык ярлы таулылар тапшыруы буенча, алар исеменнән, тирән йөрәктән әйтә бу кушаматны. Һәм алар — Орджоникидзе, Сөләйман — кайнар итеп кочаклашалар.

В. Брагинның «Эрджикинэз» исемле пьесасындагы бу урын матур, җылы һәм тирән тәэсирле итеп эшләнгән. Реалистик күренешләрдә бирелгән бу момент, бер үк вакытта, бик күп нәрсәне үз эченә алган көчле, символик күренеш булып та хезмәт итә. Пәрдә ачылгач та, тау халыклары съездында Сергоның ялкынлы кыска речендән соң ук бирелгән бу күренеш, Ленин һәм Сталин тарафыннан Россиянең Көньягына Гадәттән Тыш Комиссар итеп билгеләнгән, большевистик партия вәкиле Серго Орджоникидзе белән Кавказ халкы, ярлы таулылар арасында уртак телнең, бердәмлекнең ничек табылуының, партия белән масса арасында куәтле бәйләнеш җебе урнаштырылуының символы булып соңра бөтен пьеса буенча сузылып бара. Һәм Сергоның нәкъ менә шул тау халыклары арасына Совет властен илтүе, урнаштыруы, ныгытуы, таулы ярлыларны байлардан, князьләрдән милли шура рәисләреннән, ак офицерлардан аерып алуы, тау халыкларының үзләре арасында дуслык урнаштыруы, аларны Советлар Кавказы өчен дошманнарга каршы коралды көрәшкә туплавы— пьесаның төп темасы булып тора да. 1918 нче елны гаять катлаулы социаль һәм хәрби шартларда яшәгән Кавказда бу җиңүгә Серго ничек ирешә соң? Җиңел түгел.

Монда большевиклык сыйфатлары җиңә: бөтен нәрсәдә массага таяну, аның күзләрен ачу, уйлату, аңа чын хакыйкатьне күрсәтә, аңлата алу, төрле халыкларга, төрле социаль катлау вәкилләренә карата, моменты таләп иткәнчә, нык уйланылган һәм дөрес бер максатка төбәлгән зирәк акыллы мөнәсәбәттә була белү аерым кешеләр аркылы массаның йөрәгенә юл табу һәм аны үз артыннан ияртү...

Нинди генә кешеләр белән эш итми ул һәм нинди генә авыр һәм бөтенләй котылгысыз булып күренгән хәлләрдә калмый ул елларны безнең Серго! Байлар, ярлылар, халыкны әле үз йогынтысында тотып килгән милли шура рәисләре, сугыш обстановкасы булуга карамастан, намаз уку өчен съезд эшен туктатып торучы делегатлар, анасыз калган яшь балалы партизан, Владикавказ шәһәре башлыгы, һөҗүм итеп килеп, шәһәрне камап алган дошманның мәкерле парламентерлары һәм аларның каты ультиматумнары, ак офицерларга хезмәт итүче крестьян солдатлар, алданган казаклар...

Боларның һәрберсе белән булган мөнәсәбәтләрдә Серго гүзәл акыллылык, тапкырлылык күрсәтә һәм шушы мөнәсәбәтләрнең тулы бер системасында, моның нәтиҗәләрендә—чын большевик җитәкче гәүдәләнә.

Пьесада шаблон яки тартынкы, фальш урыннар юк. Анда без тарихи фактларга, Серго биографиясенә нигездә каршы килми торган кызыклы сюжет, җылы хисләр, кыю хәрәкәтләр, тирән дулкынландыручан вакыйгалар һәм ситуацияләр, эчке һәм тышкы чуарлыкка бай булган җанлы образлар күрәбез.

Пьесаның үзәгендә—Серго, әлбәттә. Бу образның безгә тулысынча җитүендә, тирән мәхәббәтебезне казануында без артист Камал III кә бурычлыбыз. Җаваплы, катлаулы, бөек образны,—бик күп төрле шартларга куела торган, күп төрле кешеләр белән мөнәсәбәттә була торган, һәм шуңа күрә, үзен сәхнәдә гәүдәләндерүчедән киң диапазон таләп итә торган Серго образын, — Камал III нигездә уңышлы башкарып чыга. Ул тик башта, беренче картинада гына үз роленә кереп җитә алмаган, үзен күрсәткәләп куйган төсле тәэсир калдыра. Ә инде шуннан соңгы барлык картиналарда да—пьесаның ахырына чаклы—Серго образын гына сәхнәдә калдырып, үзен бөтенләй оныттыра. Бу соңгы сыйфат исә артист өчен гомумән бик зур уңыш ул. Нәтиҗәдә без, карт Сөләйман белән яшь Кәримнең аның иң якын дуслары һәм таянычлары булып әверелүенә дә, үзләрен горур тотучы шәһәр башлыгының, дошман офицерларының ахмак хәлгә калдырылуына да, Сергоның әсирлеккә төшеп тә, солдат Левшинны, «чит ил легионы солдаты» казакны үз ягына аударып, үлемнән котылуына да, котылгысыз хәлдә дошманнар кулына Сөләйманның Серго урынына үз улы Кәримне тотып биреп җибәрүенә дә һәм Кәримнең бу рольгә керүдә һич тә икеләнмичә, үлемгә баруына да, тау халыклары ярдәме белән, Серго җитәкчелегендә, Владикавказның дошман кулыннан яңадан яулап алынуына да—барысына, барысына да,—үзебез шулай теләгән өчен яки тарихта шулай булганлыкка таянып кына түгел, ә пьесада күрүебез нәтиҗәсендә ышанабыз. Монда баш рольләрне бик уңышлы үтәүче артистларның һәм яхшы, җайлы, төпченүле итеп, барлык мизансценаларны да нык җентекләп эшләгән постановщикларның (В. Бебутов постановкасы, режиссер Х. Сәлимҗанов) хезмәтләре басым ясап әйтерлек зур. Бу пьесаны караганнан соң артист К. Шамил (Сөләйман), Сәлимҗанов (Кәрим), Сәгыйтов (Левшин) иптәшләргә безнең ихтирамыбыз аеруча артты. Үз рольләрен яхшы башкарып чыгучылардан Таждарова (Власьевна), Солтанов (Бельский), Болгарская (тол хатын), Уразиков (Терпугов), Халитов (поручик фон Дорн), Гафуров (Баталин), Булат (рәис) ларны күрсәтеп үтәргә кирәк.

Тәрҗемәнең теле (З. Солтанов) яхшы, шома.

Кавказ! Бу—илебезнең иң матур һәм бай почмакларыннан берсе һәм беренчесе. Без үз Кавказыбызны аеруча көчле һәм тирән мәхәббәт белән яратабыз. Художник Сперанскийның бу матур Кавказны сәхнәдә күрсәтүе уңышлы, сокландыргыч. Бары тик соңгы пәрдәдәге биек, текә тау түбәсенә сылап урнаштырган авылы гына тамашачыда реаль тәэсир калдыра алмый.

Пьесада күрсәтелгән вакыйгалардан 23—24 ел үткәннән соң бу сөекле Кавказыбыз яңадан кан коюлы сугыш кыры булып әверелде. Ләкин Кавказ байлыгына һәм матурлыгына комсыз һәм пычрак кулларын сузган немец-фашист илбасарлар анда үзләренә кабер генә таптылар. Пьесаның беренче картинасында символик бер урын бар: Серго, яшь балага карап, киләчәк турында уйлый. Еллар үтәрләр, алдагы зур героик бәрелешләрдә без бергә булырбызмы? Әллә мин ул чакта булмаммы?—ди ул.

Серго юк хәзер. Ләкин Совет власте тирәсенә, большевистик партия тирәсенә башлап Серго тарафыннан тупланган батыр тау халкы бөек ватан сугышында явыз немецларны Сергоча ялкынлы йөрәк һәм каты кул белән изеп ташлады, Кавказдан куды. Серго, Киров кебек титан большевиклар, «Эрджикинэзләр» тәрбиясен алу бәхетен күргән, бөек Ленин—Сталин байрагы астына бердәм тупланган безнең Кавказ халыклары һичбер нинди эчке дә, тышкы да князьләргә, бароннарга һичкайчан буйсынмадылар һәм буйсынмас! Немец этләр Кавказ тауларында хәзер моны үз җилкәләрендә бик яхшы татыдылар.

Әле бик яңа булган тарих турында дөрес һәм матур итеп сөйләүче «Эрджикинэз», шулай итеп, безнең бүгенге көнебезгә килеп тоташуы, ватан өчен көрәшкә чакыруы һәм рухландыруы белән дә уңышлы, актауль пьеса.

ГАЗИЗ ИДЕЛЛЕ.

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

СОЮЗНИКЛАР ЭЛЬ-ХАММАМА РАЙОНЫН АЛГАННАР

ЛОНДОН, 28 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Алжирдан союзниклар гаскәрләре штабының белдерүен тапшыра. Бу белдерүгә караганда күчәр державаларының гаскәрләре Эль-Хаммама районын ташлап китәргә мәҗбүр булганнар.

Союзникларның Төньяк Африкадагы гаскәрләре штабының белдерүендә аңлатуынча, союзникларның гаскәрләре Марет районыннан көньяк-көнбатышта да алга барганнар. Пленныйлар алынган.

ЛОНДОН, 28 март. (ТАСС). Англия газеталарының хәрби күзәтүчеләре Тунистагы сугышларның беренче стадиясенә йомгак ясап, түбәндәге нәтиҗәгә киләләр: хәзер Тунис фронтындагы хәл стабильләшкән булырга кирәк. Хәзерге вакытта һәр ике як үзләренең көчләрен яңа урыннарга туплыйлар.

Англия информация министрлыгының хәбәр итүенчә, Марет районында 300 квадрат миль мәйдандагы дүрт яклы оборона системасын күчәр державаларының 80.000 гә якын гаскәрләре саклый. Алардан 40 меңе немец гаскәрләре, 40 меңе итальяннар. Оборонаның бу системасы Габес, Марет, Эль-Хаммама, Матмата аркылы үтә торган позицияләр белән чикләнгән.

ФРАНЦИЯ ЭШЧЕЛӘРЕ ГЕРМАНИЯГӘ БАРУДАН БАШ ТАРТАЛАР

ЛОНДОН, 28 март. (ТАСС). Франциянең гомуми хезмәт конфедерациясе секретаре Альбер Гиги шушы көннәрдә Лондонга килде. Ул, матбугат вәкилләренә, Франция профсоюзлары хәзерге көндә яшерен рәвештә генә эшләп киләләр, дип белдерде. Шуңа да карамастан, Франциянең бөтен территориясендә профсоюзлар яшиләр һәм ике миллион ярымнан артык эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне берләштерәләр.

Франция эшчеләре Германиягә мәҗбүри эшкә җибәрелүгә каршы нык көрәш алып баралар. Шул уңай белән 1942 нче елның октябрендә Франциянең күп кенә промышленность үзәкләрендә забастовкалар ясалган. Забастовкалар нәтиҗәсендә кайбер шәһәрләрдә эшчеләрне Германиягә җибәрү ике—өч ай буенча тукталып торган. Лавальнең хыянәтчел политикасына каршы Франция эшчеләренең оешкан рәвештә каршылык күрсәтүләре дәвам итә.

Англия бомбардировщикларының Берлинга һөҗүме

ЛОНДОН, 28 март. (ТАСС). Англия авиация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, 28 нче мартка каршы төндә Англия бомбардировщиклары берләшмәләре Берлинга бик зур һөҗүм ясаганнар. Бомбага тоту тупланган рәвештә алып барылган. Бик күп бомбалар ташланган.

27 нче мартта Англия самолетлары Голландиядә һәм Төньяк-Көнбатыш Германиядә дошманның коммуникацияләренә күп кенә һөҗүмнәр ясаганнар.

—◇—

Югославия партизаннары Италиягә барып кергәннәр

ЛОНДОН, 28 март. (ТАСС). АФИ агентлыгының Цюрихтагы хәбәрчесенең язуына караганда, шушы көннәрдә Югославия партизаннары Италиянең чик буендагы бер районына үтеп кергәннәр һәм андагы берничә поездны шартлатканнар.

—◇—

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— Норвегия патриотлары Киркенес янында 4.000 кешелек итеп эшләнгән Германия хәрби лагерен яндырганнар. 52 бинадан 49 ы бөтенләй янып беткән.

— Шарлеруаның күмер районында (Бельгия) бер группа патриотлар бер үк вакытта 15 ярдәмче электр станциясе шартлатканнар. Шул ук районда Пьетон депосында 17 паровоз юк ителгән.

— 21 нче мартта якшәмбе көнне Бельгиядәге барлык чиркәүләрдә бельгиялеләрне көчләп Германиягә эшкә озатуга каршы протест йөзеннән Бельгия католик чиркәве башлыгының өндәмәсе укылган.

— 1 нче ноябрьдән алып 20 нче мартка кадәр Америка авиациясе Европада дошман объектларына 28 тапкыр һөҗүм иткән. 40.000 тоннадан артык бомба ташланган һәм дошманның 329 самолеты юк ителгән.

—Февраль аенда АКШ ның хәрби диңгез флоты 20 миллиметрлы 40 миллион данә зенит снарядлар алган. Шуңы елның 3 ае эчендә Америка флотына узган бөтен ел эчендә алынганга караганда 40 миллион снаряд артыграк алынган. Бер үк вакытта диңгез флоты ай саен, узган бөтен ел буена эшләнгәнгә караганда да, күбрәк торпедалар алачак.

Квислинг 300 мең кешене Германиягә каторгага җибәрә

СТОКҺОЛЬМ, 28 март. (ТАСС). Швециядә чыга торган «Дагенс нюхетер» газетасының хәбәр итүенчә, Квислинг Норвегиядән яңадан 300 мең кешене Германиягә җибәрергә карар биргәнлеген игълан иткән. Бу газетаның язуынча, Квислинг шушындый юл белән беренчедән, Германиягә эш көчләре җибәрү турында немецларның ныклы таләпләрен үтәргә, икенчедән, Норвегиядә милли азатлык хәрәкәтендә иң актив катнашучылардан котылырга тели.

—◇—

АМЕРИКА АВИАЦИЯСЕНЕҢ МЕССИНГА ҺӨҖҮМЕ

НЬЮ-ЙОРК, 26 март: (ТАСС). Америка бомбардировщиклары 24 нче мартта көндез Сицилия атавындагы Мессинга һөҗүм иткәннәр. Һөҗүм нәтиҗәсендә тимер юл складларында янгыннар чыккан.

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

ФРОНТКА ХАТ

Без сезнең белән, кадерле фронтовиклар

Бөгелмә районы, «Тигез басу» колхозы члены иптәш Зәйдуллина Миңҗиһанга үзенең иптәше хезмәт итә торган частьтан хат килде. Бу хат Миңҗиһан апага һәм колхозның барлык членнарына рәхмәт һәм котлау хаты иде. Рота командиры лейтенант иптәш Чижик әлек «Тигез басу» колхозында бригадир булып эшләгән Зәйдуллин Мөдәррисның югары дисциплиналы булуы, һәм командованиенең приказларын үтәүдә аеруча үрнәк күрсәтүе, шулай ук Орджоникидзе шәһәре өчен барган сугышларда батырлык һәм кыюлык күрсәтүе өчен командование тарафыннан акчалата һәм Төньяк Осетин АССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан Почет грамотасы белән бүләкләнүен белдереп, ротаның батыр сугышчылары исеменнән барлык колхозчыларга сугышчан һәм туганлык сәламын җибәрә.

Рота исеменнән килгән бу хатны колхозчылар гомуми җыелышта укыдылар һәм фронтка түбәндәге җавап хатын яздылар.

«Кадерле сугышчылар һәм безнең авылдашыбыз Мөдәррис Зәйдуллин! Сез тыныч булыгыз: гитлерчы этләрне бетерү өчен ватан сугышы фронтында батырлыклар һәм геройлыклар күрсәтүче данлыклы Кызыл Армиябезгә, аның батыр сугышчыларына бөтен көчебез белән ярдәм итәрбез һәм фронтка авыл хуҗалыгы продуктларын, сугыш коралларын һәм башка кирәк-яракларны тагын да күбрәк бирү өчен үз-үзебезне аямыйча эшләрбез.

Без, «Тигез басу» колхозы членнары 1942 нче елда дәүләт йөкләмәләрен тулысынча һәм арттырып үтәдек. Танклар колоннасы төзүгә 50.000 сум, авиаэскадрильялар төзү фондына 26.000 сум, Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән сугышчыларга бүләк итү өчен 14 000 сум акча һәм башка төрле әйберләр җыеп тапшырдык.

Без 1943 нче елда да югары уңыш алу өчен барлык көчебезне биреп көрәшәбез. Чәчүлек орлыкларын тулысынча әзерләп, чистартып һәм анализдан үткәреп куйдык. Агротехника чараларын яхшы итеп үткәрдек. Авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлауны һәм сбруйларны төзәтү эшләрен тәгәлләдек. Безнең колхоз язгы чәчүгә тулысынча әзер. Без сезнең белән, кадерле фронтовиклар.

Сәлам белән «Тигез басу» колхозы членнары».

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 31 нче мартта—**«Ильдар».**

Зур драма театры. Бүген һәм 31 нче мартта — **«Украина далаларында».**

Яшь тамашачылар театры. Бүген — **«Мәзәкчеләр».**

Дәүләт циркы. Бүген өч бүлектә **зур цирк тамашасы.** Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татарстан дәүләт филармониясе. Бүген Татар дәүләт академия театры бинасында зур **эстрада концерты.**

«Электро» яңа документаль фильм — **«Сталинград».** «Унион»— **«Партизаннар Украина далаларында».** «Пионер» — көндез **«Руслан һәм Людмила»** һәм **«Боксерлар»,** кич — **«Дуслык».** «Чаткы» —**«Моряк кызы».**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—73—27, Редактор урынбасары АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре 78—93, типография 36—60.

ПФ 1092 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 584